# КАРАР

30 ноябрь, 2023 ел № 1

## Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 30 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Чура авылы юлларына вак таш салу һәм аларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;
- Югары Чура авылына насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су суырту манараларын, су саклау зоналарын карап тоту, су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү;
- Югары Чура авылы автомобиль кичүен ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу; тракторчы-машинист хезмәтләре;
- Югары Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү;
- Югары Чура авылында су суырту манаралары янына видеокамералар һәм видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру; видеокамераларны һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;

- Югары Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылында су суырту манаралары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;

- Югары Чура авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 474 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 247 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 247 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2700 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә карар кабул иттек:

- Югары Чура авылы юлларына вак таш салу һәм аларны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылы юлларына вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, карап тоту, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- Югары-Чура авылына насослар сатып алу, урнаштыру, артезиан скважиналарын, су саклау зоналарын карап тоту;

- Югары Чура авылы автомобиль кичүен ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу; тракторчы-машинист хезмәтләре;

- Югары Чура авылында балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү;

- Югары Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары Чура авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары-Чура авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм йорт хуҗалыкларын гамәлдәге линиягә тоташтыру; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Югары -Чура авылына су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, территорияне карап тоту һәм төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: В.Н. Андреев